**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 7 ноябрь № 840

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 май, 366 нчы һәм 2015 ел, 1 апрель, 204 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Мәсьәләнең эчтәлеге» бүлекчәсенең бишенче һәм тугызынчы абзацларында тиешле килешләрдәге «белем бирү учреждениеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«2004 елның 11 октябрендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2014 – 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру

нәтиҗәләре» бүлекчәсенең сигезенче абзацында «югары һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «югары белем бирү оешмалары» сүзләренә «урта һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге дәүләт программасына 2 нче кушымтада:

3.7 пунктта:

3.7.1 пунктның 8 графасында «-» билгесен «1» санына алмаштырырга;

3.7.3 пунктның 8 графасында «2014-2020 еллар» юлында «12» саннарын «7» санына алмаштырырга;

4.1 пунктның 4.1.2 пунктчасындагы 8 графада «2 бер., 140 б.б., 3200 данә» сүзләрен «2 бер., 90 б.б., 1800 данә» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктның 1 графасында һәм 4.3.1 пунктның 4.3 графасында «Татарика» халыкара мәдәни журналы басмасын озата бару» сүзләрен «TATARICA» халыкара мәдәни журналы басмасын озата бару» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктның 3.7.3 пунктчасындагы 5 графада «белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\840.docx